КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 август г.Казань № 682

Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу буенча комиссия төзү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

«Бөтенроссия халык санын алу турында» 2002 ел, 25 гыйнвар, ФЗ-8 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Об образовании Комиссии Правительства Российской Федерации по проведению Всероссийской переписи населения 2020 года» 2017 ел, 29 сентябрь, 1185 нче карары нигезендә һәм Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының үзара хезмәттәшлеген яраштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча комиссия төзергә.

2. Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча комиссия турында нигезләмәне һәм аның составын (кararга теркәләләр) расларга.

3. 2019 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) башлыкларына, комиссия рәисе вазыйфаларын йөкләп, 2020 елда Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча район, шәһәр комиссияләрен оештырырга;

Дәүләт статистикасы органнарына билгеләнгән тәртиптә шәһәр һәм авыл торак пунктларындагы торак һәм торак булмаган фонд йортлары буенча төзелеш төрен (торак яки торак булмаган фонд) һәм төзелеш балансында булган оешма, предприятие исемнәре күрсәтелеп, адреслар исемлеген актуальләштерү һәм

оештыру планнарын төзү өчен торак урыннары саны һәм яшәү урыны буенча торак урыннарында яшәүче һәм теркәлгән затлар саны турында мәгълүматлар тапшырырга;

муниципаль берәмлекләрдә урам исемнәренең, йортларның номерлары һәм фатирларның номерлары булуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2010 елда Бөтенроссия халык санын алу турында» 2008 ел, 14 апрель, 223 нче;

«2010 елда Бөтенроссия халык санын алуны әзерләүгә һәм үткәрүгә ярдәм күрсәтү буенча республика комиссиясе составына үзгәреш кертү турында» 2008 ел, 25 июнь, 424 нче;

«Татарстан Республикасында 2010 елда Бөтенроссия халык санын алуны әзерләүгә һәм үткәрүгә ярдәм күрсәтү буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 20 апрель, 249 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 14 апрель, 223 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында 2010 елда Бөтенроссия халык санын алуны әзерләүгә һәм үткәрүгә ярдәм күрсәтү буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 31 июль, 534 нче;

«Татарстан Республикасы территориясендә 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алуны оештыру турында» 2010 ел, 15 март, 135 нче;

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары арасында Татарстан Республикасы территориясендә 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алуны иң яхшы әзерләүгә һәм үткәрүгә конкурс оештыру турында» 2010 ел, 19 апрель, 277 нче;

«Татарстан Республикасы территориясендә 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алуны иң яхшы әзерләүгә һәм үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары арасындагы конкурс йомгаклары буенча муниципаль берәмлекләрне бүләкләү турында» 2010 ел, 27 декабрь, 1125 нче.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының социаль-икътисадый мониторинг буенча комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 15 август, 682 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча комиссия
составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, комиссия рәисе |
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Гатауллина Наталья Вячеславовна | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе (килешү буенча), комиссия рәисе урынбасары |
| Кандилов Валерий Петрович | Татарстан Республикасының социаль-икътисадый мониторинг буенча комитеты рәисе, комиссия рәисе урынбасары |
| Краснова Ольга Михайловна | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстанстат) буенча территориаль органы җитәкчесе урынбасары, комиссии секретаре (килешү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Габделганиев Фәрид Солтан улы | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Бирюкова Елена Анатольевна | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстанстат) буенча территориаль органының халык статистикасы һәм сәламәтлек саклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры |

| | |
|---|---|
| Владимиров Николай Михайлович | Татарстан халыклары Ассамблеясе Советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гәрәев Раил Рүзәл улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген яраштыру идарәсе башлыгы |
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | Татарстан Республикасының югары уку йортлары ректорлары советы рәисе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры |
| Гревцов Андрей Борисович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Гомәров Рөстәм Фәрит улы | Россия Федерациясе Хәрби милли гвардиясе федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Зарипов Айрат Ринат улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Зарипова Эльмира Әмир кы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Җәббаров Азат Галимҗан улы | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Кузнецов Артём Александрович | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Кузнецова Регина Викторовна | «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсе – «Россия почтасы» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директоры (килешү буенча) |
| Мозаффарова Ленара Әкъмәлетдин кызы | «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Мөхәммәтҗанов Фиргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (гомуми тәртип саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |
| Погодин Сергей Николаевич | Татарстан Республикасының хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Семенова Ольга Юрьевна | Татарстан Республикасының социаль-икътисадый мониторинг буенча комитеты рәисе урынбасары |
| Терентьев Андрей Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәү федераль хезмәте идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Фәйзуллин Ирек Энвар улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Хамаев Азат Кыям улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры. |